ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦПАЛЬ РАЙОНЫ
ӘҖМӘКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

# КАРАР

“22” октябрь 2020 ел Яңа поселок №9

**“Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлегенең Әҗмәкәй авыл халкының үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында”**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы “**Әҗмәкәй** авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының нигезендә

## КАРАР БИРӘМ:

1. Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлегенең Әҗмәкәй авылында Вахитов, Ә.Кутуй, Г.Ибраһимов, З. Закиров, К. Тинчурин, М. Җәлил, Н. Җиһанов, Җиңү, Тукай, Х. Такташ, Х. Туфан, Үзәк, Мәктәп, Ш. Усманов урамнары, Вахитов тыкрыгы буйлап 2020 елның 13 ноябрендә 18.00 сәгатькә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

2. Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлегенең Әҗмәкәй авылында Азатлык, Әфлисун, Батыр, В.Цоя, Түп, Кунакчыл, Акчалата, Җиләкле, Күзкәй, Урман, Юкә, Мармелад, Хыяллар, Тыныч, Дөнья, Тәңкә, Тауасты, Көнбагыш, Раздольная, Ратная, Туган, Романтиков, Сабантуй, Спорт, Бәхетле, Тополиная, Уңыш, Иртәнге, Хирург Шәкүрова, Чаллы, Шифалы, Алмагач урамнары буйлап 2020 елның 14 ноябрендә 15.00 сәгатькә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

3. Халык җыенын уздыру өчен Әҗмәкәй авылында яшәүчеләрнең исемлеге аерым бүленә, сайлау тәртибе территориаль билге буенча башкарылырга тиеш.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
“Әҗмәкәй авыл җирлегенең Әҗмәкәй авылы территориясендә 2021 елда балигъ булган, Әҗмәкәй авыл җирлегенең Әҗмәкәй авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 1000 (бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, Әфганстанда, Чечняда сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылар,

чернобыльчеләр-ЧАЭСТА авария ликвидаторлары, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне:

- юлларны ремонтлау;
- электроматериаллар сатып алу, урамнарны яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыруны
- балалар уен спорт мәйданчыгын төзекләндерү;
- тукталыш павильоннары төзекләндерү

хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме

“ӘЙЕ” “ЮК”.

5.Татарстан Республикасы, Тукай районы, Әҗмәкәй авылы, Үзәк урамы, 35А йорт адресы буенча гражданнар җыенын үткәрергә.

6. Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге башкарма комитетын халык җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

7.Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

8.Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында “авыл җирлекләре” бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

9. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көннән үз көченә керә.

Әҗмәкәй авыл җирлеге Башлыгы Р.Ф.Адиев